# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кичкетаң авыл җирлеге " муниципаль берәмлегенең Барҗы-Омга торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

30 ноябрь 2025 ел № 2

Гамәлдәге законнар нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына таянып, 2025 елның 19 ноябрендә

9 сәгать 00 минутта узган гражданнар җыены буенча беркетмә төзелде.

Җыенда каралган сораулар:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Кичкетаң авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең Барҗы-Омга торак пунктында 2026 елга гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча норматив-хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерүгә бәйле рәвештә гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы 30.10.2025 №1 карарны гамәлдән чыгарырга ризамы? «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары үз көчләрен югалткан дип танылды.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 81 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 42 кеше, бу 51,8 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында 42 катнашучы тавыш бирде;

Җыенда «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

2.“Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кичкетаң авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Барҗы-Омга торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән

(махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекле хезмәткәрләр) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (бергә яшәгән ата-аналары , ире яки хатыны, балигъ булган балалары), I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән өлкән яшьтәге ялгыз гражданнардан, көндезге формада укучы студентлардан, Россия армиясе сафларына  вакытлы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан һәм ирektән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш), 2026 елда үзара салым акчаларын 900 сум күләмендә кертергә һәм ул акчаларны җирлек өчен әһәмиятле  түбәндәге эшләргә юнәлтергә ризамы?

1) Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (лампалар, дроссельләр, фонарьлар, электр товарлары һәм урамнарны яктырту өчен материаллар сатып алу һәм алмаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка чыгымнар);

2) Торак пункт территориясен төзекләндерү (газон һәм чүп үләннәрен чабу; юлларны кардан чистарту, тракторны карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, трактор өчен запас частьләр, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

3) 3) Баржы-Омга торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (чокырларны ремонтлау өчен  вак таш сатып алу һәм  салу һәм автомобиль юлларын карап тоту буенча башка чыгымнар);

г) Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча беренчел чаралар күрү (ягулык-майлау материаллары, янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр сатып алу һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка чыгымнар).

д)  Каты көнкүреш калдыкларын туплау мәйданчыклары булдыру, каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү.

«РИЗА»                                        «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 81 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашкан катнашучылар саны 42 кеше, бу 51,8 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында 42 катнашучы тавыш бирде;

Җыенда «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы "Әгерҗе муниципаль районының «Кичкетаң авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Барҗы-Омга торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кичкетаң авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Барҗы-Омга торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән (махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекле хезмәткәрләр) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан ( бергә яшәүче ата-аналары , ире яки хатыны, балигъ булган балалары), I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән өлкән яшьтәге ялгыз гражданнарны көндезге формада укучы студентлардан, Россия армиясе сафларына вакытлы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш), 2026 елда үзара салым акчаларын 900 сум күләмендә кертергә.

3. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт территориясен төзекләндерү (газон һәм чүп үләннәрен чабу; юлларны кардан чистарту, тракторны карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, трактор өчен запас частьләр, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау (җәяүлеләр күперләрен ремонтлау өчен материаллар сатып алу).

4. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Кичкетаң авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең Барҗы-Омга торак пунктында 2026 елга гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча норматив-хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерүгә бәйле рәвештә

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кичкетаң авыл җирлегенең мәгълүмат стендында игълан итәргә, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru)

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Муниципаль берәмлек башлыгы И.Н.Җиһангәрәев